Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл җирлеге Советы Карары

25 октябрь 2019 ел № 108

Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә, авыл җирлеге Советы җирле салымнар буенча недоимканы, пеня һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану өчен өстәмә нигезләр билгеләү турында Карар кабул итте:

1. Җирле салымнар буенча недоимканы һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә (алга таба - бурыч) өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү:

- үлгән физик затлар милкенә һәм җир салымына өч елдан артык бурыч барлыкка килү датасы буенча яисә Россия Федерациясе Граждан процессуаль законнарында аларның вафатлары дип игълан ителгән тәртиптә;

-үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затлар милкенә салым һәм җирсалымы буенча мирас ачылганнан соң бер ел дәвамында мирас алмаган очракта,мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган очракта;

- җир салымы буенча 2006 елның 1 гыйнварына кадәр недоимка һәм (яки) пеня һәм штрафлар буенча бурычлар барлыкка килгән очракта.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Г.Х.Гарипова